**ГЛАВА ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**№ 20-ПГ** **2019 елның 4 апреленнән**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгының 2018 елның 24 июленнән №66-ПГ “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм сроклары турында Кагыйдәне раслау турында”гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга, 2006 елның 2 маеннан №59-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы Федераль законга, 2017 елның 27 ноябреннән №355-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законга, Татарстан Республикасының 2003 елның 12 маеннан №16-ЗРТ “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында”гы законына ярашлы төстә, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгының 2018 елның 24 июленнән №66-ПГ “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм сроклары турында Кагыйдәне раслау турында”гы карарына кушымтага ярашлы төстә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).
3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне Район Советы аппараты җитәкчесе И.М.Хантимеровка йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы** **М.П.Афанасьев**